**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Советы**

КАРАР

«19» декабрь 2025 ел № 7

**Олы Әтнә авыл җирлеге Советы 11.11.2019 ел 128 номерлы карары белән расланган «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2025 елның 21 апрелендәге №84-ФЗ Федераль законына («Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен гамәлдән чыгару һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законның 14 һәм 15 нче статьяларына үзгәрешләр кертү турында») һәм 12.12.2025 елдагы № 020802-2025/Прдп362-25 номерлы Әтнә районы прокуратурасының протесты буенча, Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы, 11.11.2019 ел, № 128 номерлы Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карары белән расланган (10.02.2020 ел, №141; 28.05.2020 ел, №148; 30.10.2020 ел, №7; 06.12.2021 ел, №39; 16.05.2022 ел, №48; 17.08.2022 ел, №52; 27.10.2023 ел, №77; 05.06.2024 ел, №89; 21.04.2025 ел, №111 үзгәрешләре белән) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1** "21 нче маддәнең 3 нче пунктының икенче, өченче һәм алтынчы абзацларында «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре ягыннан» дигән сүзләрдән соң «(муниципаль партнер түләве, капиталь грант күләме)» дигән сүзләр өстәргә;

**1.2.** "21 нче статья, 3 нче пункт, дүртенче абзацтагы «Бу чикләү таралмый» дигән сүзләрне «Бу пунктның икенче һәм өченче абзацларындагы чикләүләр таралмый» дигән сүзләр белән алыштырырга."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Россия Федерациясенең Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Олы Әтнә авыл
җирлеге башлыгы: Хисамиев Р.Ш.